***Нәҗметдинова Әнисә Зәки кызы***



*Мин, Нәҗметдинова Әнисә Зәки кызы, 1941нче елның 23 нче июлендә Зур Битаман авылында туганмын. Безнең әтиебез сугышка киткән. Сугыштан соңгы балачаклар бик авыр еллар буып истә калган. Ашарга юньләп юк, кычыткан, кузгалак, акы ише үләннәр җыеп ашыйбыз. Күкәрин күмәче пешерә иде әниебез. Зур Битаман авылында 7 класс белем алдым. Беркайдан да ярдәм күрмәдек. Әтиебез сугыштан яраланып кайтты. Без аның исән кайтуына бик куандык. Шулай авырлыклар белән тормыш дәвам итте.*